

Рузаевка районы житәкчесе Александр Сайгачев Татар Пешләсе авылынын Жинvнен 40 еллыгы урамында яшәvче-ләр белән очрашты. Быел алар урамы буенча юл ремонтланачак.
Татар Пешләсенен Садовая урамыннан Южная, Совет урамнарына кадәр асфальт тvшәләчәк. Яна юл озын булачак, барлыгы - 1600 метр. Бу халыкны соендерде, чонки алар әлеге карарны берничә дистә ел коткәннәр. Алга таба анын буенча 10 нчы номерлы автобус маршрутын озайту планлаштырыла.      Аннары Александр Сайгачев, Татар Пишләсе авыл жирлеге башлыгы Ринат Давлюк улы Шабаев белән бергә, ремонт таләп итә торган башка урамнар белән танышканнар.
Эшләнелгән эшләре дә байтак аларнын.  2020 елда Южная урамындагы юл катламын янартканнар, анын буенча яктырткычлар элгәннәр. Тагын биш километр грунт юлларын вак таш белән каплаганнар. Быел Совет һәм Колхоз урамнарын тоташтыручы тыкрыкта каты ослек барлыкка килгән.  «Авыл территорияләрен комплекслы vстерv» программасында актив катнашу сәбәпле, биредә спорт мәйданчыгы барлыкка килгән, якташ язучыбыз Шәриф Камалнын туган урыны то-зекләндерелгән. Алга таба танылган язучы бюстын урнаштыруны планлаштырганнар.